ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2021 г.Лениногорск № 250

Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең Административ регламентларының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 26 ноябрендәге 7036 номерлы, 2020 елның 24 декабрендәге 7483 номерлы, 2021 елның 15 гыйнварындагы 7507 номерлы, 2021 елның 26 гыйнварындагы 7522 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опекун (попечитель) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 2 ноябрендә под-1148/20 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Банкта яки башка кредит оешмасында счет (кертемдә) булган балигъ булмаган балага караган акчаны ябу, исәптән төшерү, күчерү, тоту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2020 елның 5 ноябрендәге под-1158/20 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алу һәм уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат буларак исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге под-1326/20 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Балигъ булмаганнарның күчемсез милкен читләштерү буенча алыш-бирешләргә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2020 елның 9 декабрендәге под-1305/20 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 4

гыйнварындагы 16/21 номерлы, 2021 елның 21 гыйнварындагы 567/21 номерлы, 2021 елның 22 гыйнварындагы 645/21 номерлы, 2021 елның 20 февралендәге 1891/21 номерлы хатлары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 8 августында 1112 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 08 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга карата опека (попечительлек) билгеләү буенча яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 8 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган балигъ булмаганнарның акчалата кертемен алуга законлы вәкиленә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 8 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган балигъ булмаганнарның күчемсез милкен читләштерү буенча алыш-бирешләргә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы Аппаратының җәмәгать оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә өч эш көне эчендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең Административ регламентларын урнаштыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

О.В. Назарчук
5-04-13